СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

17.11.2022 с. Набережные Моркваши 27-161

Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022нче елның 28 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Яр буе Морквашы авылы Кәрим Тинчурин урамындагы җирле әһәмияттәге юлларны һәм Урман урамы буенча 5 нче һәм 7нче йортларга юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 40 йорт (Башкарма комитет бинасы) адресы буенча 13.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов